**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

Чернышевский урамы, 23нчейорт
Лаеш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024 елның 26 марты 414 номер

**КАРАР**

**Балигъ булмаганның акчалата кертемен аның законлы вәкиле алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 8 апрелендәге 770 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Гаилә кодексы нигезендә 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (19.12.2022 редакциясендә), «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын уллыкка (кызлыкка) алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында 2013 елның 8 апрелендәге 770 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А. Г. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**